**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_17__» __03__ 2025 ел.** **№ __59__**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 345 номерлы «2020-2026 елларга Азнакай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 мартындагы 370 номерлы «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында»гы карары нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 345 номерлы «2020-2026 елларга Азнакай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында»гы карарына (19.10.2021 №263, 15.12.2021 №326; 03.11.2022 №343, 20.12.2023 №325 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның исемендә һәм бөтен тексты буенча «2020-2025» сүзләрен «2020-2026 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» төзелешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Программа чараларын финанслау планлаштырыла торган елларда федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла, финанслау күләме дәүләт заказчысы - Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгы тарафыннан бүленү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

| ел | Фаразланган чаралар күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | Федераль бюджет | Бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2020 | - | - | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2021 | 562 462,25 | 116 917,15 | 1 585 218,6 |
| 2022 | 1 360 900,95 | 489 094,05 | 3 435 705,00 |
| 2023 | 2 801 564,13 | 734 021,07 | 6 566 086,8 |
| 2024 | 1 872 445,49 | 627 583,51 | 4 642 911,00 |
| 2025 | 694 100,00 | 2 230 700,00 | 5 431 771,4 |
| 2026 | 688 837,21 | 2 213 786,46 | 5 390 586,8 |
| 2027 | 688 790,23 | 2 213 635,44 | 5 390 219,1 |

*Чараларны финанслау күләмнәре Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгында конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru, «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанслар буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов